СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески, Арский
муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«25» июнь 2026 ел** **№ 28**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2022 елның 4 августындагы 55 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкының Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән үзгәртү турындагы мәсьәләне тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, Иске Кырлай авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча карта-схема (1 нче кушымта) нигезендә 2026 елның 27 июленә ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны үткәрү урыны итеп түбәндәгеләрне билгеләргә: Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Советы бинасы; Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт, үткәрү вакыты 13 сәгать 00 мин..

3. Ачык тыңлаулар уздыру турында хәбәрнамәне һәм 2 нче кушымта нигезендә проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Иске Кырлай авыл җирлегенең рәсми стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә: Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12а йорт, 2026 елның 28 июленә кадәр.

4. 2026 елның 28 июленә кадәр ачык тыңлаулар йомгакларын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Иске Кырлай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә: Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай урамы, 2 йорт, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12а йорт.

5. Ачык тыңлаулар уздыру комиссиясе составын расларга (3 нче кушымта).

6. Билгеләргә:

ачык тыңлауларны оештыручы - ачык тыңлауларны уздыру комиссиясе;

7. Ачык тыңлаулар уздыру комиссиясенә:

әлеге карар белән билгеләнгән сроклар нигезендә ачык тыңлаулар әзерләүне тәэмин итәргә;

ачык тыңлаулар беркетмәсен, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм рәсмиләштерергә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.


Иске Кырлай авыл җирлеге
башлыгы

Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы Иске Кырлай
авыл җирлеге Советы карарына
1 нче кушымта

## Карта-схема
границ муниципальных образований
с учетом изменений



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы

Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карарына

2 нче кушымта

**Проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе**

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән үзгәртү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр карта-схема нигезендә Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча кертелә: Түбән Мәтәскә ав., Тукай урамы, 2нче йорт яисә 88436656293 телефоны буенча, язма рәвештә ачык тыңлаулар тамгасы белән

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлег” муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән үзгәртү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр эш көннәрендә 2026 елның 24 июленә кадәр 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт адресы буенча яисә почта аша (конвертка «ачык тыңлаулар» тамгасы белән) яисә 88436656293 телефоны буенча бирелә.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан теркәлә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Иске
Кырлай авыл җирлеге Советы
карарына
3 нче кушымта

Ачык тыңлаулар уздыру комиссиясе
составы

| ФИО | Вазыйфа |
| --- | --- |
| Лутфуллин Фаниль Фәнәвил улы | Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы |
| Гыйләҗиев Хәйсәр Равил улы | «Иске Кырлай төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ директоры, Иске Кырлай авыл җирлегенең 3 нче округы депутаты |
| Низамиев Фаргать Нурияздан улы | Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Гайнетдинов Ильдар Борхан улы | "Д. Г. Хәкимов исемендәге Түбән Мәтәскә УББМ" МБМУ директоры, Иске Кырлай авыл җирлегенең 6 нчы округ депутаты |
| Сираҗетдинов Фаргать Гарафетдин улы | Иске Кырлай авыл җирлегенең 5 нче округ депутаты |